2. Конкурсның максатлары

2.1. Конкурсны уздыруның төп максатлары түбәндәгеләр:

а) укучыларда иҗади һөнәрләргә, шул исәптән, журналистикага карата кызыксыну уяту;

б) районда мәктәп матбугаты хәрәкәтен үстерүгә булышлык итү;

в) гуманитар юнәлештә сәләтле яшьләрне эзләү һәм алар белән эшләү.

3. Конкурсны оештыручылар

3.1. Мәктәп матбугат чаралары арасында уздырылучы «Яңа офык» бәйгесенең оештыручылары түбәндәгеләр:

а) «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле белем бирү учреждениесе

б) «Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе

в) ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы – «Актаныш таңнары» Мәгълүмати-мөхәррият үзәге.

4. Конкурсны уздыру тәртибе

4.1. Конкурс ике өлештән тора. 1 өлеш – **2014 елның 1 октябреннән 2014 елның 15 декабренә кадәр**. Бу вакыт эчендә катнашучылар материалларын җибәрәләр.

Нәтиҗәләр ясап, җиңүчеләрне билгеләү – **2014 елның 18 декабрендә.**

4.2. Конкурста катнашырга теләгән мәктәпләр һәм мәктәп матбугат чарасы мөхәрриятләре жюри хөкеменә түбәндәге төрдә материаллар җибәрә алалар:

а) газета яки журналның соңгы елда чыгарылган берничә санын;

б) радиотапшыруның чыгарылышларын (аудиоязмада);

в) телетапшыруларның чыгарылышларын (видеоязмада);

г) электрон матбугат чарасы (адресы теркәлгән гариза)

4.3. Катнашучылар үз материалларын электрон почтага җибәрә яки гимназия-интернатка китерә ала.

5. Конкурска нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

5.1. Бүләкләү түбәндәге номинацияләр буенча каралган:

а) “Иң яхшы төп мәктәп газетасы”

б) “Иң яхшы урта мәктәп газетасы”

в) “Иң яхшы эшләүче мәктәп радиосы”